МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.06.2017 Казан шәһәре № под-1058/17

«Оста мөгаллим» грантын алуга
Республика конкурсы турында

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының иң яхшы укытучыларының татар телендә укыту процессын оештыру, мәктәп укучыларының полилингваль белем бирү сыйфатын арттыру, татар телендә белем бирү буенча мәктәп яшендәге балалар белән эшне оештыруга инновацион якын килүен ачыклау һәм бүләкләү, шулай ук иң яхшы педагогик тәҗрибәне тарату максатында б о е р а м:

1. «Оста мөгаллим» грантын гамәлгә куярга.

2. Кушымта итеп бирелгән :

2.1. 2017 елда «Оста мөгаллим» грантын алуга республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планын (алга таба-Конкурс);

2.2. «Оста мөгаллим» грантын алуга республика конкурсы турында Положениене расларга.

3. Конкурсны 2017 елның 21 июленнән 2 августына кадәр оештырырга һәм үткәрергә.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 2.1 пункты белән расланган план үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. Ф. Гатиятуллина) конкурсны оештыруны һәм уздыруны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Милли мәгариф бүлегенә (А. С. Шәрипова) боерык кабул ителгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р. Мөхәммәтовка йөкләргә.

Татарстанр Республикасы
Премьер-министр урынбасары –министр Э.Н. Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының
14.06.2017 № под-1058/17
боерыгы белән

2017 елда «Оста мөгаллим» грантын алуга Республика конкурсын оештыру һәм үткәрү чаралары Планы

| № | Чара | Үткәрү сроклары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында Конкурс турында мәгълүмат урнаштыру (конкурс шартлары, таләпләр, үткәрү вакыты) | 2017 елның 13 июленә кадәр | Г. Х. Исмәгыйлева<br>А. С. Шәрипова<br>А. А. Кравцов |
| 2 | Республика эксперт комиссиясе эшен оештыру | 2017 елның 21 июленнән 28 июленә кадәр | Г.Х. Исмәгыйлева<br>А. С. Шәрипова |
| 3 | Республика күләмендә грант алучылар исемлеген формалаштыру | 2017 елның 2 августына кадәр | Республика эксперт комиссиясе |
| 4 | Массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан конкурс барышын яктыртуны оештыру | Конкурс барышында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугать хезмәте |

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының
14.06.2017 ел № под-1058/17
боерыгы белән

«Оста мөгаллим» грантын алуга республика конкурсы турында

Положение

1. Гомуми положениеләр

1.1. «Оста мөгаллим» (алга таба - Грант) гранты Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела (алга таба - министрлык).

Чарада грантны гамәлгә куючы (алга таба - грант бирүче), грантка дәгъва кылучы һәм грант алучы катнаша.

Грант бирүче - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Министрлык.

Грантка дәгъва кылучы - Татарстан Республикасы мәгариф системасының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һәм конкурс сайлап алуын узган, әлеге Положениедә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган физик зат.

Грант алучы-конкурс сайлап алуын узган һәм 1дән 50 гә кадәр урын алган.физик зат

Грант- физик затлар кеременә салым һәм Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына, Мәҗбүри медицина иминиятенең федераль фондына иминият взносларын исәпкә алмыйча гына, ай саен 6 500 (алты мең биш йөз) сум күләмендә бирелә торган акчалата түләү

1.2. Грант алуга конкурс сайлап алу максаты:

балаларны татар телендә укыту процессын оештыру буенча Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының иң яхшы укытучыларын ачыклау һәм бүләкләү;

укучыларның полилингваль белем сыйфатын күтәрү;

татар телендә белем бирү буенча мәктәп яшендәге балалар белән эш оештыруның инновацион алымнарын тарату;

нәтиҗәле педагогик тәҗрибәне пропагандалау һәм тарату.

1.3. Сайлап алу Конкурсыныж бурычы: Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының татар телендә белем бирүче укытучыларын алга таба профессиональ компетенцияләрен күтәрүгә, иҗади потенциалларын үстерүгә стимуллаштыру.

1.4 Грантны алуга конкурста катнашырга хокуклы затлар:

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү татар телендә алып барыла торган белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү буенча төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, яисә белем бирү татар телендә алып барыла торган мәктәпләрнең математика, информатика, химия, физика, биология, география, тарих, җәмгыять белеме, физик культура, технология, тормыш иминлеге нигезләре фәннәре рус телендә алып барыла торган сыйныфларында эшләүче беренче һәм югары квалификацияле укытучылар шулай ук башлангыч сыйныф укытучылары;

Һөнәри эшчәнлектә зур нәтиҗәләр күрсәткән, үзләренең педагогик тәҗрибәсен актив тараткан өчен 2016 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә ярдәм күрсәтү грантында җиңүче укытучылар,

1.5. Грант алуга конкурста Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтү буенча «Укытучы - остаз», «Укытучы - эксперт», «Укытучы-мастер», «Өлкән укытучы» номинацияләрендә җиңүчеләр катнаша алмый.

2. Грант алу өчен гаризалар кабул итү һәм конкурс сайлап алу тәртибе

2.1. Грант алуга Конкурс (алга таба - Конкурс) Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.2. 2017 елның 13 июленнән дә соңга калмыйча конкурс турында мәгълүмат (конкурс шартлары, таләпләр, аны үткәрү вакыты) “Интернет" мәгълүмати-

телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла (http://mon.tatarstan.ru).

2.3. Грантка дәгъва кылучылар әлеге Положениенең 1 һәм 2 нче кушымтасында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны электрон почтага “osta - mogallim@mail.ru адресы буенча 2017 елның 20 июленнән дә соңга калмыйча тапшыра.

Гаризаны 2017 елның 20 июленнән соңга калып тапшырган очракта, грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.4. Конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итүне һәм уздыруны 9 (тугыз) кеше составында республика эксперт комиссиясе гамәлгә ашыра.

2.5. Республика эксперт комиссиясе хокуклы:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесеннән (алга таба Республика олимпиада үзәге), «Республика белем бирү сыйфатын мониторинглау үзәге» дәүләт бюджет учреждениесеннән (алга таба республика белем бирү сыйфатын мониторинглау үзәге), муниципаль мәгариф идарәсе органнарыннан һәм башка оешмалардан комиссия эше өчен кирәкле мәсьәләләр буенча материалларны һәм мәгълүматны соратып алырга;

кирәк булганда, өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты», Республика олимпиада үзәге, Республика белем бирү сыйфатын мониторинглау үзәге, мәгариф белән идарә итү муниципаль органнары белгечләрен, конкурс материалларына өстәмә экспертиза үткәрү өчен җәлеп итәргә.

2.6. Республика эксперт комиссиясе утырышларын республика эксперт комиссиясе Рәисе, ә ул булмаганда - Республика эксперт комиссиясе рәисе урынбасары җитәкли

2.7. Республика эксперт комиссиясе утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса гына, тулы хокуклы булып санала.

2.8. Республика комиссиясе карарлары, алар өчен катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта - .кабул ителгән дип санала, Тавышлар саны тигез булса, Республика комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була.

2.9. Республика эксперт комиссиясе 2017 елның 21-24 июлендә документлар буенча конкурс сайлап алуы, тәкъдим ителгән гаризаларга башлангыч экспертиза үткәрә. Документларның һәр пакетына карата, документларның әлеге Положение таләпләренә туры килүе турында эксперт бәяләмәләре. язма рәвештә. Республика эксперт комиссиясенең ике әгъзасы тарафыннан төзелә.

2.10. Тәкъдим ителгән материалларны анализлау нәтиҗәләре буенча, агымдагы елның 27-28 июлендә узачак сайлап алу этабына республика эксперт комиссиясе тарафыннан, әлеге Положение таләпләренә туры килә торган гаризалар сайлап алына.

2017 елның 25 июленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасында электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәсе органнарына турыдан-туры сайлап алу үткәрү графигы җибәрелә.

2.10. Республика эксперт комиссиясе шәхси әңгәмә рәвешендә, грантка дәгъва кылучыларны сайлап алуның турыдан-туры этабын уздыра. Әңгәмә вакытында республика эксперт комиссиясе документларны тикшерү нәтиҗәләрен, шул исәптән тапшырылган материалларны анализлаганда ике эксперт күрсәкән кимчелекләрне яңадан карый. грантка дәгъва кылучы әңгәмә барышында 5 баллы шкала буенча бәяләнә. Республика эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0дән 5 кә кадәр баллар куела. Нәтиҗәдә, һәр грантка дәгъва кылучыга, барлык экспертларның бәяләмәсен исәпкә алып, уртача балл чыгарыла. Җыелган баллар рейтингыннан чыгып, Положениенең 1.1 пунктында күрсәтелгән санда җиңүчеләр билгеләнә.

2.11. Конкурс нәтиҗәләре буенча республика эксперт комиссиясе тарафыннан, 2017 елның 2 августына кадәр грант алучылар исемлеге төзелә һәм раслана.

2.12. Республика эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, комиссия рәисе,ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары тарафыннан имзалана

2.13. Грант бирүче 2017 елның 5 августына кадәр грант алучыларның расланган исемлеген үзенең (http://mon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыра

## 3. Сайлап алу Конкурсы критерийлары

3.1. Грантка дәгъва кылучы укытучының:

соңгы 3 ел дәвамында Бөтенроссия предмет олимпиадаларының муниципаль этабында җиңгән, һәм/яки призлы урын алган укучыларыбулырга;

укытучы-соңгы 3 ел дәвамында Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында җиңүче һәм призер булырга;

грант алучы башлангыч сыйныф укытучыларының соңгы 4 ел дәвамында Республика һәм/яки Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадаларының муниципаль этабы җиңүчеләре һәм призерлары булырга;

соңгы 3 ел эчендә һөнәри осталык бәйгеләренең ("Ел укытучысы") муниципаль яки республика этапларында җиңүче һәм призер булырга тиеш.

3.2. Соңгы өч елда бердәм дәүләт имтиханнарында укучыларның канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләре, төп дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча төп гомуми белем турында (билгеләнгән фән буенча өлгермәү сәбәпле) аттестат алмаган укучылары булган, ,шулай ук республика белем бирү сыйфатын бәяләү системасы кысаларында бәяләү процедуралары канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләр күрсәткән башлангыч сыйныф укытучыларына (2-4 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләре, белем бирү сыйфатын тикшерү) конкурста катнашу рөхсәт ителми

3.3. Грантка дәгъва кылучы белем бирү оешмасының штаттагы хезмәткәре булырга тиеш.

4.4. Конкурста катнашкан чорда грантка дәгъва кылучы ягыннан дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар бирү ачыкланса, грант бирү турында карар кабул ителми.

3.5. Грант бирүче апелляция комиссиясе төземичә генә конкурска йомгак ясау хокукын үзендә калдыра.

## 4. Грантны Финанслау

4.1. Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Кушымта №1
“Оста мөгаллим”грантын алуга
Республика конкурсы турындагы
Положенигә

| Татар телендә укытучы укытучылар |
| --- |
| 1. Шәхси мәгълүмат белән Анкета<br>2. Фән укытучылары өчен 5 документ: 2-3 укучы дипломы, 1-2 укытучы дипломы<br>соңгы 3 ел эчендә бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүче һәм/яки муниципаль этап җиңүчеләре турында;<br>укытучы - соңгы 3 ел дәвамында Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында җиңүче булу һәм/ яисә призер булу турында<br>3. Башлангыч сыйныф укытучылары өчен 5 документ: 2-3 укучы дипломы, 1-2 укытучы дипломы<br>соңгы 4 ел дәвамында республика һәм/яки бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль этабы җиңүчеләре һәм/яки призерлары булу;<br>укытучы - соңгы 3 ел дәвамында Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында җиңүче һәм/яки призер булу турында.<br>4. Дәлилләү хаты<br>Татар телендә белем бирүче мәктәпләрдә тьюторлык һәм остазлык эшенең проблемалары, үсеш перспективалары, бу эшкә нинди өлеш кертә алуыгыз һ.б турында үз фикерләрегезне әйтеп 500-700 сүзлек дәлилләү хаты языгыз<br>5. 2017 елга һөнәри үсеш планы / остазлык эше<br>6. Татарстан Республикасы муниципаль районы мәгариф бүлеге (идарәсе) җитәкчесеннән бәяләмә (шаблон нигезендә_ |

Кушымта 2
"Оста мөгаллим" грантын алуга
республика конкурсы турында
Положенигә

Оста мөгаллим" грантын алу
өчен Республика эксперт комиссиясе
Рәисенә

"Оста мөгаллим" республика грантына дәгъва кылучыга

Бәяләмә

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, эш урыны)

*(грантка дәгъва кылучыга характеристика бирелә, ни өчен бу укытучы грант алырга тиеш икәне, алга таба һөнәри үсеш перспективасы күрсәтелә)*

Грант алырга теләүченең БДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек булмаган һәм төп гомуми белем турында аттестат алмаган (билгеләнгән фән буенча өлгермәү сәбәпле), белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасы кысаларында, бәяләү процедураларының 2-4 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләрен соңгы өч елда белем бирү сыйфатын тикшерүнең канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләре юк дип раслыйм.

Татарстан Республикасы (муниципаль район исеме)
Мәгариф бүлеге (идарә) башлыгы / /

МП

Дата: